Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
2013 елның 24 июлендә теркәлде, 1948

# Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты

## БОЕРЫК

**25.06.2013** **Казан ш.** **№ 24 – ОС**

### “Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турында” Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының 2007 елның 26 октябрендәге 210-К номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турында “Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турында” Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының 2007 елның 26 октябрендәге 210-К номерлы боерыгы (алга таба – Боерык) белән расланган нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4-1.4.2 пунктларның үз көчен югалтуын танырга;

Нигезләмәнең “Гомуми нигезләмәләр” дигән 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле пунктлар өстәргә:

“1.4. Комитетта түбәндәге очракларда конкурс уздырылмый:

а) Комитетта граждан хезмәте вәкаләтләрен билгеле бер срокка биләнүче вазыйфаларга “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрен билгеләп куйганда;

б) сроклы хезмәт контракты төзелгәндә;

в) “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә каралган очракларда, граждан хезмәткәрен бүтән вазыйфага билгеләп куйганда;

г) конкурс нигезендә булдырылган кадрлар резервында торучы граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп куйганда.

1.5. Комитет рәисе карары буенча граждан хезмәтенең кече төркеменә караган граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куйганда конкурс уздырылмаска да мөмкин.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда уздырыла:

Россия Федерациясе гражданының сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә дәүләт граждан хезмәтенә керә алу хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфа буенча үсү хокукын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен иң яраклы кандидатларны федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар арасыннан сайлап алу;

Комитетның кадрлар резервын булдыру”;

2.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Конкурс комиссиясе утырышын бары тик Комитетта граждан хезмәте вазыйфасын биләүче әгъзалары катнашында гына уздыру тыела.”;

3.2 пунктта “30 көн эчендә” сүзләрен “21 көнлек срокта” сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәнең 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә: “3.3. Үзе граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органындагы конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре эшкә яллаучы вәкиле исеменә гариза бирә.

Бүтән дәүләт органындагы конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре эшкә яллаучы вәкиле исеменә шул органга гариза тапшыра һәм үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм үзе граждан

хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органындагы кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган анкетасын фотографиясе белән бергә тапшыра.”;

4.1 пунктның 4.1.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Конкурс уздыру турында урнаштырыла торган мәгълүмат хәбәрендә граждан хезмәте вакантлы вазыйфасының атамасы, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъвачыга карата таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында “Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы белән расланган нигезләмәнең 7 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итү тәмамлана торган срок, конкурсны уздыруның күз алдында тотыла торган датасы, аны уздыру урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмат материаллары күрсәтелә.”;

4.1 пунктның 4.1.1 пунктчасында “30 көн эчендә” сүзләрен “21 көнлек срокта” сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктта”бер ай эчендә сүзләрен “7 көнлек срокта” сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында “Конкурста катнашу өчен ________ тапшырыла” сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“ ______________ дәүләт хезмәтен узу шартлары”.

2. Юридик сектор әлеге Боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис урынбасары

О.Ю. Семенова